СОВЕТ ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.06.2020 г. Заинск № 525

**Аренда түләүләрен түләүдән азат итү өлешендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм чаралары турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм чаралары турында» 2020 елның 19 мартындагы 670-р номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте күрсәтмәсенә, «Яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында иң күп зыян күргән Россия икътисады тармаклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 03 апрелендәге 434 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 821-р номерлы күрсәтмәсенә, Зәй муниципаль районы Уставына нигезләнеп, Зәй муниципаль районы Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. Зәй муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль казнасын тәшкил иткән муниципаль милекне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен (алга таба – муниципаль милек) арендалау шартнамәләре буенча түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

а) «Яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында иң күп зыян күргән Россия икътисады тармаклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 03 апрелендәге 434 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган исемлеккә кергән яңа коронавирус йогышы таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында Россия икътисады тармакларында эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы, кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән арендаторлар - кече һәм урта эшкуарлык субъектлары белән мөрәҗәгать иткән көннән алып 7 эш көне дәвамында 2020 елның апрель-июнь айлары өчен аренда түләүләрен түләүдән азат итүне күздә тоткан өстәмә килешүләр төзү.

Күрсәтелгән аренда түләүләрен түләүдән азат итү, әгәр дә аренда килешүендә, күрсәтелгән эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен, аннан файдалану максатларында, муниципаль мөлкәтне арендага бирү каралган булса, һәм күрсәтелгән эшчәнлек төрен (эшчәнлек төрләрен) гамәлгә ашыру өчен тиешле мөлкәтне куллануны раслаучы документлар булганда гамәлгә ашырыла;

б) Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының рәсми сайтында арендаторлар – кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен әлеге пунктның «а» пунктчасы нигезендә өстәмә килешүләр төзү мөмкинлеге турында мәгълүмат урнаштыруны.

2. Әлеге карар нигезендә күрсәтелгән аренда түләүләрен түләүдән азат итү Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертелгән датага әлеге карарның 1 пунктындагы «а» пунктчасында каралган эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча узган чорга аренда түләүләрен түләү буенча бурычлары булмаган, кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән арендаторлар - кече һәм урта эшкуарлык субъектларына карата гамәлгә ашырыла, дип билгеләргә.

3. Зәй муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына әлеге карарның үтәлеше турында Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына 2020 елның II кварталыннан башлап, кварталдан соң килүче айның 10 числосыннан да соңга калмыйча, мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

4. Карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының рәсми сайтында (www.zainsk.tatar.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, икътисадый үсеш һәм муниципаль милек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**